КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 февраль г.Казань № 111

2023 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен саклау чаралары турында

2023 елгы язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм халыкны, хуҗалык һәм торак объектларын, гидротехника корылмаларын, юлларны һәм күперләрне саклау максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2023 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен саклау чаралары планын (алга таба – План) расларга.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча барлык дәрәҗәләрдәге комиссияләренә – түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук Планда күрсәтелгән җирле үзидарә органнарына һәм оешмаларга гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

План чаралары үтәлешен тәэмин итүне;

гадәттән тыш хәлләрне бетерү эшләре белән җитәкчелек итүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 ноябрь, 480 нче карары нигезендә гамәлгә ашыруны;

2023 елның 1 апреленә кадәр – Планны тормышка ашыру турындагы һәм 2023 елның 16 маена кадәр язгы ташу узу нәтиҗәләре хакындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына кертүне.

3. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына 2023 елның 1 июненә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 2023 елда Татарстан Республикасы территориясендә язгы ташу нәтиҗәләре турында мәгълүмати-аналитик хисап тапшырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен саклау чаралары турында» 2022 ел, 21 гыйнвар, 33 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин